# КАРАР
## Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Келәнче авылында гражданнарга үзара салым кертү турында

18 нче ноябрь 2022 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авылында гражданнар җыены **карар итте** :

1.Үзара салым 2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700,00 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау ( сатып алу, ташу, вак таш җәю, су торбаларын урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү ) Келәнче авылында Татарстан һәм Г. Тукай урамы буенча урнашкан.;

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) Келәнче һәм Бәки авылларында;
- Келәнче һәм Бәки авылларында юлларны грейдлау, кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Келәнче һәм Бәки авылларында авылны төзекләндерү (иске хуҗасыз төзелешләрне сүтү, шәхси киртәләрне сүтү, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- чишмә территориясен төзекләндерү ( төзелеш материаллары сатып алу, павильон урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).;
- Келәнче авылында зират коймасын ремонтлау ( төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;
- каты көнкүреш калдыкларының вакытлыча полигоннарын тоту һәм чистарту( килешү буенча эшләр өчен түләү);
- янгын машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау (яна трубалар сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча түләү).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Келәнче авылы, Г.Тукай урамы, 35;

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәки  авылы, Фрунзе урамы, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Келәнче  авыл җирлеге
башлыгы: Д.А.Кадыров.